ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши,
422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Красавин ур., 40 нчы йорт, Яр Буе Морквашы авылы,
422594

Тел.: (84379) 3-16-47, факс: (84379) 3-16-47.

10.11.2023 № 2

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 10 ноябрендә «Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?- Урман Морквашы авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау, дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 57 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 13 кеше кертелгән.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында гражданнар җыены узмады, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә түгел дип танырга.
2. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында авылындагы гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И.Х.Гаязов